Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Торнаяз авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«07» ноябрь 2025 ел № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 7 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Торнаяз поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 гр.инвалидлардан кала, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге бүлектә укучы студентлар, СВОда катнашучылардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм әлеге кертемнәрне түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту җайланмасы;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 163 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 86 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 86 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Торнаяз авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Торнаяз поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 гр.инвалидлардан кала, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге бүлектә укучы студентлар, СВОда катнашучылардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм әлеге кертемнәрне түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту җайланмасы;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авылы торак пункты мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.Г. Еливанова

Заречный авыл җирлеге башлыгы Л.Г. Еливанова